...Укып сине ишетәм хәбәрләрне
Уныш теләп торам көчле халкыма.
Сезнен белән мин дә бергә диеп,
Шатлыгымнан йөрәк талпына.

Шулай безнен “Юлдаш» газетасын яратып 5 куплетлы шигырь (югарыда озек) яза Мәскәүдә яшәүче Шәяхмәт Мохәммәтша улы Жиганшин. Ул 1946нчы елда Горький олкәсе Кызыл Октябрь районы Шоба (Шубино) илендә туа.

Шоба мәктәбендә белем алганнан сон, Арзамас техникумында авыл хужалыгын механизацияләү һәм электрофикацияләү бүлеген тәмамлый, Советлар Армиясе сафында ракетчик булып хезмәт итә, батарея комсомол секретаре дә була. Аннары, 1969-2009нчы елларда Мәскәү автомобильләр жыю заводында (ОАО «Москвич». Автомобильный завод АЗЛК) слесарь-сборщик, инженер, баш механик, цех житәкчесе, генераль директорнын урынбасары булып хезмәт итә.Тырыш хезмәтенә күпторле бүләкләре дәлил.. Шәяхмәт Мохәммәтша улы тормыш иптәше Зәкия Равиль кызы Салехметова (тумышы белән Торбеево районы Татар Йонәсе авылыннан) белән гаилә корып тату гомер итәләр. Зәкия Равиль кызы Мордовия педагогия институтын тәмамлап, гомере буе укытучылык итә; туган Татар Йонәсе авылы мәктәбендә дә, Мәскәүдә дә. Жиханшиннар ике кыз бала, Альфия белән Голсемне тәрбияләп үстерәләр; бүген - югары белемле белгечләр. Аларнын балалары - Роберт белән Алина, әби-бабайларын шатландырып үсәләр. Шәяхмәт Мохәммәтша улы белән Зәкия Равиль кызынын балалары бүген Мәскәүдә пенсионер әти-әниләренә ярдәм итеп яшиләр. Унган кеше барлык яктан унган, диләр, бу чынлап та шулай. Шәяхмәт Мохәммәтша улын алтын куллы дип тә әйтергә була: лаеклы ялга чыккач, үз проекты буенча, гаражлы, мунчалы дача сала. Бакчаларында нәрсә генә үстермиләр алар, керсән - сокланырлык! Барлык эш-гамәлләре белән бергә, күнел очен, шигырьләр дә яза Ш. М.Жиганшин. 20дән артык шигырь язган инде. Шәяхмәт Мохәммәтша улы Торбеево районы Татар Йонә авылына кунакка кайткач дуслашып китә дә инде Мордовия республикасында нәшер ителә торган «Юлдаш» газетасы белән. Хисләре күнеленен ин тирән почмакларыннан ургылып шигъри юлларында чыга. «Укып сине ишетәм хәбәрләрне.Уныш теләп торам кочле халкыма.Сезнен белән мин дә бергә диеп, шатлыгымнан йорәк талпына»,- дип тә

куя «Юлдаш» газетасына багышлап язган шигырь юлларында. Кин кvнелле кеше ул. Татар Йонәсе кызын гына тvгел, Мордовияне, халкын да ярата Шәяхмәт әфәнде. Шул яраткан халкына ана телендә, булдыралган дәрәҗәдә, шигырьләр яза. Якташ язучыбыз Хади Такташка да поэма багышлый. Аннан озек:

...Карыйм шул син йөргән урамнарга
Чыгарсын дип кинәт юлыма.
Исәнме син мишәр Шәяхмәт диеп,
Сузарсын диеп кулын кулыма.
Никтер сине кvргем кели
Тавышынны иштеп карап кvзенә.
Мин дә сина сәлам бирер идем
Кочып, ирегеп, сөеп, ярап vзенә.

Н.Хәлил